| ГЛАВА<br>Иж-Бобьинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Иж-Бубый авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2025 Иж-Бубый авылы № 03

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 1нче этабын 2025 елның 12 октябрендә 13сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынының 2нче этабын 2025 елның 12 октябрендә 15әгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга:

-1 этап: 1 нче Колхоз тыкрыгы. 2нче Колхоз тыкрыгы, Елга аръягы урамы, Колхоз урамы, Урман урамы, Яшьләр урамы, Татарстан урамы һәм тыкрыгы, Хезмәт урамында яшәүчеләр.

- 2 этап: Ижау урамы, Магистраль урамы, Яр буе урамы, Яңа урам, Үзәк урамда яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәттә авыру алган инвалидлардан, 80 яшькә

җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекленәр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

1) Иж-Бубый торак пунктының зиратының коймаларын ремонтлау, яңаларын кору, төзекләндерү (зират территориясендә кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган авария хәлендәге һәм корыган агачларны кисү; Иж-Бубый торак пункты зиратын төзекләндерү, коймалар кору өчен материаллар сатып алу һәм башка чыгымнар);

2) Иж-Бубый торак пункты территориясен төзекләндерү (газоннарны һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм Иж-Бубый торак пункты территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

3) һәйкәлләр төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (якташларыбыз - Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәйкәлен ремонтлау өчен чыгым материаллары сатып алу;

4) Иж-Бубый торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар сатып алу һәм алмаштыру; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

5) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларга түшәү өчен вак таш сатып алу һәм салу; автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар;

6) Иж-Бубый торак пунктында яшәүчеләрне су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргеч челтәрен төзү һәм ремонтлау, торак пунктны су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

7) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (мотопомпа сатып алу һәм башка чыгымнар)

“КИЛЕШӘМ” “КАРШЫ”

5. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Иж-Бубый авылы, Үзәк урам, 20нче йорт, авыл мәдәният сарае адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Ваһапов